# ӘДӘБИ
# альманах

# Әдәби

# Альманах

Күпербаш җидееллык мәктәбе
әдәбият түгәрәге членнары
иҗаты.

Түгәрәк җитәкчесе укытучы
Г. Фазылҗанов редакцияләде.

1953-54 уку елы.




Әдәбият түгәрәге членнары

(1953-54 уку елы)

## Шаяхметов Фәрит шигырьләре.



### Мәктәпкә ашыгам.

Шинди матур бүген көн,
Йөгереп урамга чыгам,
Күңелле уйлар белән
Мин мәктәпкә ашыгам.

Ашыгам мин мәктәпкә
Атлыйм кызулабрак
Барышлыйка берьякки
Атлап керәм мәктәпкә.

Беренче звонок була,
Без класска керәбез;
Зур түземсезлек белән
Укытучыны көтәбез.

# Үлемсез шагыйрь

Моабитның төрмәсендә
Каты режим куелган
Токлы чыбыклар сузылган
Стенасы буеннан.

Газаплыйлар кешеләрне
Моабит төрмәсендә;
Көндә үлем, каты җәза
Бу төрмә тирәсендә.

Бу төрмәгә ябылганнар:
Көрәшчеләр, батырлар,
Муса кебек Ватан сөйгән
Патриот шагыйрьләр.

Ул кызганмаган тормышын,
Нык торып үлә белгән.
Иң соңгы минутларында да
Зур җиңүнең иле өчен
Якын булуын күргән.

## Сакларбыз туган илне.

Тау тирәсендә
Дошман кыйналган,
Җимергән борнын
Козгын җыйналган.

Чик бозып кергән
Үч безнең илгә,
Хуҗа булырга
Безнең зур җирдә.

Ләкин алдакган
Бу явыз дошман,
Үзе күпләр аннан
Булганнар корбан.

Без таптатмабыз
Дошманга җирне,
Уяу сакларбыз
Зур, туган илне.

## Сакчы

Илнең чигендә
Яшь сакчы тора,
Винтовкасының
Курогын бора.

## Комсомол

Безнең илдә комсомоллар
Зур-зур эшләр башкара,
Чирәм җирләрне эшкәртергә
Озатты аларны Башкала.
Башкаланың ышанычын
Акларга сүз бирәләр,
Ленин комсомоллары — алар
Һәр фронтта җиңәләр.

# Клубта

Клубка яшьләр җыела,
Эштән соң ял итәргә;
Газета укып-белем алып
Уйнап, көлеп китәргә.
Гармунчылары да килгән,
Яшьләрне биетергә;
Эшләп арган аякларны
Кирәк бит селкетергә.
Биеп китә Гали дә,
Аңа каршы Мансура;
Барысы да тырышалар
Матуррак басарга.
Хәбип абый да үкенә,
Яшьтән әйләнүенә;
Исе китеп карап тора,
Яшьләрнең биюенә.
Клуб ишеге төбендә
Динислам абый да тора,
Тайпылгандагы җөйләрен
Сабир абзый да бора.

Тик шулай, безнең яшьләр
Күңелләрен ачалар,
Клубка килгән картлар да
Йөрәкләрен басалар.

## 5 март

Бишенче март көнендә
Кайгы килде халыкка
Башларын түбән иделәр
Һәр илдәге халык та.

Бу көннең авырлыклары
Мәңге калыр йөрәктә,
Юлбашчының истәлеге
Нык сакланыр халык та.

Янамагыз сез, дошманнар,
Курыкмыйбыз без сездән;
Уйламагыз сез алырга,
Изге җирләрне бездән.

## Яшелчә бакчасында

Без тордык иртүк
Эшкә барырга.
Яшелчәдән мул
Уңыш алырга.

Килдек бакчага
Эшкә зур теләк
Ибраһим бабай
Тоттырды көрәк.

Эшләдек яхшы,
Кызганмый көчне
Кич кайттык өйгә
Йөз кочак төсле.

## Чаңгы шуганда

Чыктык без кырга
Чаңгы шуарга;
Ярышып уйнарга,

Күрдек бер куян
Бардык артыннан
Тәмам ардырып
Тоттык ботыннан.

Салдык капчыкка
Йөгердек өйгә,
Тунадык аны
Кайткач без өйдә.

Тирене киереп,
Куйдык кибәргә;
„Менә, дип, акча
Безгә дәфтәргә".

Килде тирене
Бирдек тирене
- Бик яхшы, - диде,
Күп акча бирде.

## Зверинцияда

Зверинцияга кергәч,
Курдек төрле хайваннар;
Аю, бүре, төлке, борсык
Юлбарыслар, маймуллар.

Маймыл таганда атына,
Попугай купшылана;
Тиен трупчада әйләнә,
Аю суга ташлана.

Без бик озак карап йөрдек
Зверләрнең төрлесен,
Ә шулай да, мин тапмадым,
Тутыйдан да ямьлесен.

## Гали.

Гали кәгатьны бик сөйгән,
Кергәч, сумкасын атты;
Кулын да юып тормады,
Табакка кулын тыкты.

Бернич кан & озатмылар.
Талап җыйган ташусине;
Суктырдылар, астырдылар
Каршы-килгэн кешене.

× × ×

Гашия бүген курыкты,
Ишеклэрен биклэде;
Тэрэзэ янына утырып,
Кулъяулыгы эшлэде.
Шул вакыт ишек каерып,
Немец керде өенэ;
Кулъяулыгын алып тыккач,
Кулын сузды шэленэ.
Табып алды бар нэрсэне,
Кыйммэттэге ашлыкны;
Менеп өстерэп тышерде,
Чормадагы сандыкны.
Салдырып алды эченнэн
Актык тышкы кулмэген,
Сатлэренэ кадэр алды,
Сате белэн чулмэгэн.

Куркып беткән мескен Гали
Чыкты качкан җиреннән
Әнисен каплап карагач,
Чыгып китте аннан.

Халыкларга җитте Гали,
Әнигә кабер казырга;
Үзе йолдоз кисеп, бер тактага
Бик тырышып кереште язарга.

Әнисен күмгәч, кайгыдан,
Ул чыгып китте кырга;
Озак утырды бер тауда,
Кыймылдамый да бер дә.

Кинәт, караса, артына
Берәү шуышып килә;
Кар өстендә ак халаты
Әкрен генә селкенә.

Чагерергә ул теләде,
Кычкырды тегә кеше:
-Бу мин, Гали, курыкма син,
Галиянең күршесе.

Бу аларның күрмәсе шул,
Таның алды ул шунда;
„Партизанга киткән" дигән
Сүз бар аның турында.

Галигә җитте бу кичә:
Без киләбез иртәгә,
Немецлар штабка килгәч,
Флаг бәйлә кертәгә.

Бик шатланып кайтты Гали,
Өен җылытып, ~~кайтты~~ ятты;
Ул түземсез көтеп яткан
Шатлыклы таң да атты.

Иртүк торып күзәтте ул
Немецларның бар эшен,
Немецларны күргән саен,
Нығырак кыса тешен.

Менә бервакыт немецлар
Җыендылар штабка,
Кызыл флагны күтәреп
Бәйләде ул шул чакта.

Күп тә тормада, урамга
Яхшы атлар керделәр;
Штаб урнашкан мәктәпкә
Цепкә тезелеп килделәр.

Бер немец чыкты бер йорттан
Гали аягын чалды,
Ул егылгач, балта белән
Әбисе үчен алды.

Штабтагы бөтен немец
Берсүзсез бирелделәр,
Менә шулай, партизаннар
Авылны азат иттеләр.

Авыл немецтан котылгач,
Гали килде кабергә
Еглап әйтте әбисенә:
– Авыл азат гомергә.

Тик сине генә бер кайгә
Тагын саклый алмадым
Картлыгыңда тәрбиячең
Ярдәмчең була алмадым, –

Диде дә, кабер өстенә
Капланып елады ул,
Туфракларын үбеп куйды,
Ул аны күрә алмый шул.
Туфрагын алып кабердән
Үбеп, Гали ант итте,
Әбисе һәм әнисе үчен
Дошманнан кайтару өчен
Партизан булып китте.

## Габделхай

Наил абый иртүк килде,
Колхозның ындырына;
Машинасын чистарты да
Китеп басты урнына.
Сугучылар да килделәр,
Бүген арыш сугарга;
Бер әби дә килеп җиткән
Кош-кортларны куарга.

Эшләделәр бер тукталмый,
Тамам хәлдән тайганчы;
Утырдылар да салкынга
Ашадылар туйганчы.

Эшләделәр кичкә чаклы,
Кичен кайттылар өйгә;
Өйләрдә утлар кабынды,
Казанда кайный өйрә.

* * *

Колхозчылар бүген бик шат
Барысы да сөенә;
Ындыр табагында зур-зур
Бодай тавы өелә.

Ләкин, Габделхәй шатланмый,
Ул кайгыла, бар үе;
Чыгып китә ул ындырдан
Белмисез барыр юлы.

Кайтыр иде ул авылга,
Көләр аннан бар халык;
Ничек кайгыны басарга,
Сөйләргә кемгә барыр.

Кердә ул тау арасына,
Утырды шунда ташка;
Кичке карангы төшкәнче,
Булды ул кузгалмаска.

Җиргә карангылык яткач,
Халык өйгә таралгач,
Габделхәй да юлга чыкты;
Инде, шәт, кеше булмас.

Кулына бер чыбык тоткан
Башы тәмам интеккән,
Уйлый-уйлый сизмәгәндә дә
Авылга килеп җиткән

Арт яктан кердә өенә,
Өйдә барсы да йокламаган;
Хатыны да зур кайгыда
Юрганын да ябмаган.

Тавышсыз өй уртасында
Озак торды Габделхәй
Эчсез торуның бер көне
Тоелды аңа бер ай.

Уй, тигез — тигезгә кенә,
Урынына килеп ятты;
Күрмәс өчен, бернәрсәне
Юрганын баштан ятты.

Уй тели, күзен йомык,
Бар эшне онытырга;
Ләкин ирек бирми уйлар
Телгән кысыктырга.

Шул вакыт урамда, туктап,
Кемнәрдер сөйләшәләр;
Габделхай сискәнеп китте,
Гүя аңладышалар.

Колаклары торды аның,
Булмый тыңламый торып;
Сүз аның турында бара
Булса кирәк кусрып.

× × ×

Берәү сөйләп китте шунда
Нәкъ Габделхай турында
Атка карашы начар, ди
Чыбыркы ди кулында.